**РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, 3-44-14, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
03.06.2019

КАРАР
ПР-125

# Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы ачык сулыкларда 2019 елгы су коену чорында су коенуны тыю турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының “Актаныш муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенен 03.06.2019 елның 9-19 санлы карары белән, Актаныш муниципаль районы территориясендә пляжлар һәм суда массакүләм ял итү урыннары булмау сәбәпле, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты, гражданнарның тормышын һәм сәламәтлеген саклау максатларында,

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елгы су коену сезоны вакытында Актаныш муниципаль районы территориясендә урнашкан ачык сулыкларда гражданнарга коену тыела.

2. 2019 елгы су коену сезоны чорында Актаныш муниципаль районының су объектлары янында халык күпләп ял итә торган урыннарда профилакт рейдлар өчен мобиль төркем составын расларга (1 нче кушымта).

3. Авыл башкарма комитетлары җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

- су коену сезоны дәвамында җирлек территориясендә ачык сулыкларда коенуны тыю һәм балаларны махсус контрольдә тоту кирәклеге турында халык белән белешмәлекләр өләшеп, аңлату эшләре алып барырга;

- балаларны караучысыз тоту һәм өлкәннәрдән контрольсез тоту рөхсәт ителгән гаиләләрне аерым контрольгә алырга, мондый гаиләләр белән шәхси профилактик эш алып барырга, ата-аналарга кул куйдырып коенуны тыю турында белешмәлекләр тапшырырга;

- ачык сулыклар янына су коенуны тыю турында аншлаглар урнаштырырга;

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль район Башкарма комитеты Җитәкчесенен социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

И. Ш. Бариев

“1 нче кушымта

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
№ ПР-125 03.06.2019

2019 елгы су коену сезоны чорында Актаныш муниципаль районының су объектлары янында халык күплэп ял итэ торган урыннарда профилактик рейдлар өчен мобиль төркем составы

Мирзаянова А. Р.-Актаныш муниципаль районы административ комиссиясе секретаре, Башкарма комитетның мобиль патруль төркемнэре эшен контрольдэ тотуны тормышка ашыру өчен җаваплы вазыйфаи заты;

Шарифьянов И. И. – Актаныш янгын сүндерү-коткару гарнизоны башлыгы (килешү буенча);

Хэйретдинов И. И. – Россия Эчке эшлэр министрлыгының Актаныш районы буенча бүлеге башлыгы (килешү буенча);

Шэфикова Н. Р. - Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «мэгариф идарэсе» МКУ җитэкчесе (килешү буенча);

Нургалиев И. И. – Актаныш муниципаль районының «ОСВОД » РОО җитэкчесе (килешү буенча);

Актаныш муниципаль районы авыл җирлеклэре башлыклары (килешү буенча);

Хөсэенов Р. В.- “Актаныш муниципаль районы Гражданлык яклау идарэсе” МКУ җитэкчесе;